**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «30» октябреннән № 299

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 25.09.2013 елның 25 сентябрендәге 406 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2014 елның 17 гыйнварындагы 16 номерлы карардагы үзгәрешләр белән)»**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү эшен оештыру турында» 2014 елның 6 октябрендәге 20-18/1241 номерлы хатын үтәү йөзеннән, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенең 1.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Гаиләнең җан башына уртача кеременә компенсация алу хокукын билгеләгәндә «Аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемнәрен исәпкә алу һәм керемен исәпкә алу тәртибе турында» Федераль законның 5-14 статьяларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча,

гаиләнең җан башына уртача keremen һәм ялгыз яшәүче гражданның дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен аларга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә исәпләнә.

Компенсацияне билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән компенсацияне билгеләү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай эчендә билгеләнә (алга таба – исәп-хисап чоры).

Гаиләнең җан башына уртача керемен билгеләгәндә, аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә, компенсация алучының ире (хатыны) булган гражданнарның керемнәре исәпкә алына.

Исәп-хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме уртача айлык җыелма керемне гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Исәп-хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез була.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык кереме аның исәп-хисап чорында алынган керемнәре суммасын әлеге керемнәр алынган шушы исәп-хисап чорындагы айлар санына бүлү юлы белән билгеләнә».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**